ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАРАТЛЫ-КИЧУСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НАРАТЛЫ-КИЧУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423714,Республика Татарстан
Мензелинский район, с.Наратлы-Кичуского, ул.
Центральная , дом 2

423714, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Наратлы-Кичу авылы, Центральный
урамы, 2

телефон: (85555)3-51-96. E-mail Narat.K@tatar.ru

**К А Р А Р**

«10» май 2018ел Наратлы- Кичү авылы №14

**Янгын сүндерүнең беренчел чаралары исемлеген раслау турында**

Минзәлә муниципаль районы авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2008 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994елның 21 декабрендәге №69-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 25 апрелендәге №390 “Янгынга каршы режим турында”гы карары нигезендә

**К А Р А Р Ч Ы Г А Р А М :**

1. Кушымта нигезендә янгын сүндерүнең беренчел чаралары исемлеген расларга.
2. Җирлекнең торак пунктлары территориясендә йорт хуҗаларына алар милкендәге индивидуаль торак йортларны, расланган исемлек нигезендә, янгын сүндерүнең беренчел чаралары белән тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм районның рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**ТР Минзәлә муниципаль районы**
**Наратлы-Кичү авыл җирлеге**
**Башкарма комитет җитәкчесе:** **Ф. Х. Минһаҗев**

1 нче кушымта
Карар
«10 » май 2018ел № 14

# ИСЕМЛЕК
## индивидуаль торак йортлар өчен янгын сүндерүнең беренчел чаралары

| Янгын сүндерүнең беренчел чаралары аталышы | саны (шт) |
|---|---|
| Су (200 литр) яки порошок (ОП-5) утны сүндергеч. | 1 |
| Штык көрәкләре | 1 |
| Совковой көрәк | 1 |
| Лом | 1 |
| Чиләк (10 литр) | 2 |
| Балта | 1 |
| Баскыч( торак йортның кәрнизенә кадәр килеп җитә) | 1 |

ИСКӘРМӘ:
Янгын сүндерү чараларын янгын очрагында файдалану өчен уңайлы урында компакт рәвештә урнаштырырга.